| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның «15» феврале Лениногорск №169

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасының 66-ЗРТ номерлы Законының гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативларының эшчәнлеге буенча дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырылу сәбәпле, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарлары үз көчен югалткан дип таныйрга:

2017 елның 7 июлендәге 921нче номерлы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Лениногорск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентын раслау турында», анда «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Лениногорск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм

(яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен башкару буенча административ регламенты расланган;

2018 елның 15 мартындагы 295 номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында», аларда «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3нче статьясының 2нче часте, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты расланган»;

2018 елның 19 апрелендә кабул ителгән 459 нчы номерлы «Акчалары күпфатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» анда күпфатирлы йортлар төзелешенә акча җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты расланган.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче Н.Р. Залаков

И.Р.Хәйбрахманов
5-44-72